МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.07.2020 г.Казань № 516

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 6 августында 6803 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр вазыйфасын башкаручы Р.Ф. Валиуллов

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 14 июлендәге 516 номерлы боерыгы белән расланган

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 254 номерлы «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 25.07.2018 ел № 703, 18.09.2018 ел № 885, 24.06.2019 ел № 494, 17.10.2019 ел № 853, 09.04.2020 ел № 238 боерыкларында кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.4.2 пунктның 2 пунктчасындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның рәсми сайтында - http://mtsz.tatarstan.ru. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.6 пунктта:

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә төзелгән» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында төзелгән» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктының «Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Нигезләмә» сүзен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карары белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү тәртибе турындагы нигезләмә» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктындагы «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр аталышы» графасында «турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы уникенче абзацта «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.11 пунктындагы «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр аталышы» графасында «хезмәт күрсәтүләр» сүзләреннән соң «, мондый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп» сүзләрен өстәргә;

2.12 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» графасында «Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)»;

2.15 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «Федераль закон» сүзләрен «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2.15 пунктның «Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Тәртип» сүзен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе» сүзләренә алмаштырырга;

2.16 пункттагы «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына таләпләр аталышы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча бирелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре»;

3.4.1 пунктчаның икенче абзацында «2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларны» сүзләрен «балаларны – » сүзләренә алмаштырырга;

3.4.2 пунктчаның икенче абзацында «2013 елның 23 октябренә кадәр туган балаларны» сүзләрен «балаларны – » сүзләренә алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 21 июлендәге «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 490 санлы боегыры белән расланган даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 7 июнендәге 317 санлы, 2017 елның 23 мартындагы 171 санлы, 2017 елның 8 июнендәге 349 санлы, 2018 елның 7 маендагы 351 санлы, 2018 елның 18 сентябрендәге 885 санлы, 2019 елның 24 июнендәге 494 санлы, 2019 елның 5 ноябрендәге 919 санлы, 2020 елның 4 апрелендәге 257 санлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә):

1.4.2 пунктның 2 пунктчасындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның рәсми сайтында - http://mtsz.tatarstan.ru. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган»;

1.6 пунктта:

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә төзелгән» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында төзелгән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «188 номерлы Нигезләмә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 7 мартындагы 188 номерлы карары белән расланган Даими чит тәрбиягә (ярдәмгә, күзәтчелеккә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү бирү тәртибе

турындагы нигезләмә» сүзләренә алмаштырырга (алга таба - 188 номерлы Нигезләмә);»;

2.5 бүлектә:

«Хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» графасында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 512 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 20 августындагы 512 номерлы «Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен гаиләнең уртача баш керемен һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен санаганда исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге турында» карары (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 512 номерлы карары)» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының кырык икенче абзацында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» графасында «Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)»;

2.15 пунктның «Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «880 номерлы Тәртип» сүзен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе» сүзләренә алмаштырырга;

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 28 июлендәге 516 номерлы «Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга, уку дәвамында ике ата-анасын да, яки бербәндер ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга пособие, субсидия, стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 ел№ 317, 22.06.2017 ел № 406, 07.05.2018 ел № 349, 18.09.2018 ел № 885, 24.06.2019 ел № 493, 12.11.2019 ел № 992, 25.02.2020 ел № 119 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга, уку дәвамында ике ата-анасын да, яки бербәндер ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга пособие, субсидия,

стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.4.2 пунктның 2 пунктчасындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның рәсми сайтында - http://mtsz.tatarstan.ru. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган»;

1.6 пунктта:

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә төзелгән» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында төзелгән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында:

«63-ТРЗ номерлы Закон» сүзләрен «2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законы» сүзләренә алмаштырырга;

«ТР КМ 542 номерлы карары белән расланган нигезләмә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмә (алга таба - ТР КМ 542 номерлы карары белән расланган нигезләмә)» сүзләренә алмаштырырга»;

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы ундүртенче абзацта «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

«Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «РТ КМ 20 номерлы карары белән расланган Тәртип» сүзләрен

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибе» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» графасында «Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)»;

2.15 пунктның «Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «ТР КМ 880 номерлы карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе» сүзләренә алмаштырырга.